**Класс:** 5

**Укытучы:** Шакирова Рузилә Рәисовна

**Программа:** Вигасин А.А. Гомуми тарих. Борынгы заман тарихы. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.

**Тема:** Бертуган Гракхларның җир турында кануны

**Максаты**: Тиберий Гракхның трибун итеп сайлану максатын ачыклау; Гракхларның кабул иткән кануннары белән таныштыру; укучыларда тарих фәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** карта белән эш, яңа терминнарны үзләштерү.

I **лекция**

-**Исәнмесез, укучылар! Бүгенге дәрестә Бертуган Гракхларның җир кануннары турында сөйләшербез. (2 слайд)**

**План**

- Чит җирләргә яулар сугышчы–игенчеләрне бөлдерә
- Тиберий Гракх – ярлыларны яклаучы
- Җир турында канун кабул ителү
- Гай Гракх абыйсының эшен дәвам итә

**(3 слайд)** Римлылар Урта диңгез буйларында үз хакимлекләрен урнаштыргач, Рим дәүләтенең үзендә яшәүче халыкның төрле төркемнәре арасында дошманлык уты кабына. Дошманлык кораллы бәрелешләргә китерә, гражданнар сугышы башлана. **(4 слайд)** Аның беренче корбаны Италия игенчеләрен яклап чыгыш ясаган халык трибуны Тиберий Гракх була.

**(5 слайд)** Игенче–сугышчы озак кына йөреп әйләнеп кайткач, җирләрен чүп үлән каплап китүен, китмән һәм уракларның урлануын, терлек абзарларының бушап калуын күрә. Хатынын гаепләү

гаделсезлек булыр иде – аңа ялгызына хуҗалык итүе авырга туры килгән. Җирен арзан хакка күршесенә сатып, игенче Римга юл тоткан.

Игенче өйдә юк чакта байлар аның җирләрен хатыныннан көч белән тартып алган чаклар да булган. **Сугыштан кайткач, игенче кемгә зарлана алган соң? (6 слайд)** Бары тик сенатка гына, ләкин анысы да файдасыз: кыерсытучының анда яклар кешесе, дусты тәгаен бар. Мөлкәтен югалткан ярлыларга бер генә юл кала – Римга. Анда ачлыктан, мохтаҗлыктан интеккән игенче–хәерчеләр тамак туйдырыр өчен акча табып булмасмы дип очраклы эш эзләп йөргәннәр.

**(7 слайд)** Рим каршында үз казанышлары белән мәгълүм, плебей нәселеннән чыккан егетнең исеме Тиберий була. Бервакыт Италия буйлап йөри. Беркайда да ирекле игенчеләр күренмәүгә аның исе китә; җир сөрүчеләр һәм көтүчеләр барсы да чит илләрдән китерелгән коллар була. Тиберий шомлана, чөнки ул үз хуҗаларына бервакытта да тугры булмаган ирексезләрнең бергә тупланыуы никадәр куркыныч нәтиҗәләргә китерүен яхшы аңлый. **(8 слайд)** Өстәвенә игенчеләрнең бөлүе Римның хәрби көчен какшата, чөнки армиягә хәерчеләрне алмаганнар. Римга кайткач, ул халык трибуны вазифасын алу өчен тырыша. Халык җыеннарында Тиберий бер кешене дә битараф калдырмый торган чыгышлар ясый: “Хәтта кыргый хайваннарның да өннәре, торыр кушлары була, - ди ул, - ә Рим өчен сугышларда йөргән кешеләрнең һава белән яктылыктан кала бернәрсәләре дә юк! Сугышчыларны дөнья хакимнәре диләр, ләкин аларның бер түмгәк җирне дә үземнеке дип атарга хаклары юк! Юк! Алар башкалар баесын һәм зиннәткә күмелеп яшәсен өчен сугышалар һәм һәлак булалар!” Б.э.к.**133** елда Тиберийны халык трибуны итеп сайлыйлар.

**(9 слайд)** Италияне басып алганда буйсындырылган халыклардан тартып алынган җирләрнең бер өлеше Рим дәүләтенең милкенә

әверелгән Тиберий яхшы белә. Әмма Рим аксөякләре иң яхшы җирләрне үзләренә эләктерәләр һәм аның белән ни теләсәләр шуны эшлиләр. **(10 слайд)** Б.э.к. **133** елда  Тиберий җир турында шундый канун тәкъдим итә: бер гаилә дә мең югердан (югер - гектарның чиреге чамасы) артык дәүләт җиреннән файдаланырга тиеш түгел. Артык җирләрне тартып алырга һәм сатарга рөхсәт ителми торган итеп, ярлы гражданнарга өләшергә кирәк.

**Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, әлеге яңа законнарны сенаторлар кабул иткәнме икән? (11 слайд)** Сенатта Тиберий яклау тапмый, Сенаторлар икенче халык трибуны Октавийны Тиберийның бу куркыныч планын өзәргә котырталар. Октавий үзе дә зур җир биләмәләренә хуҗа була һәм алар белән килешә. Ул, үзенең  вето хокукыннан файдаланып, Халык җыелышында бу канун өчен тавыш бирүне тыя. Шунда Тиберий Җыелышка мөрәҗәгать итә: “Халыкка зыянга эшләүче кеше трибун булып кала аламы?” – дип сорый. Аңа җавап итеп гражданнар Октавийга каршы тавыш бирәләр һәм аны трибунлыктан алып ташлыйлар. Шуннан соң Җыелыш җир турында канун кабул итә.

**(12 слайд)** Җир бүлү белән Тиберий җитәкчелек итә, ә аңа энесе Гай Гракх булыша. Байлар ярсып каршылык күрсәтәләр. Алар, Тиберийны каралтып күрсәтергә теләп, аның максаты ярлыларның хәлен яхшырту түгел, ә дөнья болгатып хакимиятне үз кулына төшерү дигән яла ягалар.

**(13 слайд)** Тиберий уйлаган планын ахырынача җиткерү өчен икенче тапкыр сайланырга тели. Чөнки ярлыларга җир өләшү бик авыр эш булып чыккан һәм озакка сузылган. Сайлаулар җәй уртасында үткәрелә. Тиберий яклылар җыелышта азрак була: күп игенчеләр кырда эшләрен ташлап китә алмыйлар. Аның каравы Тиберийга каршылар, мәкерле план корып,  тавыш чыгаралар. **(14 слайд)** Тиберийның бер дусты, көчкә генә аның янына килеп: “Саклан, трибун! Янәшәңдәге

храмда сенат җыелышы. Анда синнән үч алырга җыеналар!” – ди. Тиберий, әйләнә–тирәсендәгеләргә үзенә куркыныч янавын белдерергә теләп, куллары белән башын тота. Аның бу хәрәкәтен дошманнары икенче төрле аңлаталар, Тиберий патша таҗын таләп итә дип кычкыралар. Шундый ялган гаеп белән алар сенатка ашыгалар. **(15 слайд)** Сенаторлар хезмәтчеләре белән шунда ук мәйданга йөгереп чыгалар. Сенаторларга халыкның ихтирамы шулкадәр зур була, алар күренүгә шундук таралып, юл бирәләр. Ә алар туп–туры Тиберий өстенә баралар, аны яклаучыларны эскәмия аягы белән кыйныйлар.

**(16 слайд)** Бу көнне өч йөздән артык римлы ерткычларча кыйнап үтерелә. Халык трибуны, Рим кануннары буенча изге һәм кагылгысыз дип саналган Тиберий Гракх та һәлак була. Төнлә аларның гәүдәләрен Тибрга ташлыйлар.

- **Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, Тиберийның эшен дәвам итүче табылганмы икән? (17 слайд)** Тиберийның үлеменнән соң тугыз ел үткәч, аның энесе Гай Гракх б.э.к. **123** елда халык трибуны итеп сайлана. Ул зур тырышлык белән җирләрне яңадан бүлүне дәвам итә. Гай сенаторлар өчен Тиберийга караганда куркынычрак булып чыккан. Чөнки ул тәвәккәл эш иткән. **(18 слайд)** Ул ике мәртәбә трибун булган һәм күп законнарны үткәрә алган. Бер закон нигезендә ул абыйсын үтерүчеләрне җәзага тарткан, икенчесе нигезендә икмәк бәяләрен төшергән. Меңләгән игенче җирле булган. Байлар Гайны күралмый башлый. Сенат Римга хәрби отрядлар кертә, шәһәр урамнары тагын канга батырыла. Гракх яклы өч мең кеше һәлак була. Дошманнарны кулына эләгергә теләмичә, Гай үзен–үзе үтерә.

**(19 слайд)** Берничә елдан соң җирләрне сатуны тыйган канун бетерелә. Байлар яңадан ярлылардан җир сатып ала башлыйлар. Италия игенчеләренең хәерчеләнүе дәвам итә.

**II практик өлеш**

**Беренче бирем**

***Тарихи хаталарны табыгыз.***

Һәр римлының дүрт исеме булган. Мәсәлән, Тиберий Семпроний Гракх. Беренчесе Тиберий – кушамат, икенчесе теге яки бу патриций яки плебей ыруыннан булуын күрсәтә. Өченче исем – Гракх – шәхси булып торган. Хатын–кызлар әнисенең исемен генә йөрткәннәр. Әгәр хуҗа үз колын ireккә җибәрсә, ул аңа үз ыруы исемен биргән.

**Җавап:**

Һәр римлының ~~дүрт~~ **өч** исеме булган. Мәсәлән, Тиберий Семпроний Гракх. Беренчесе Тиберий – ~~кушамат~~ **шәхси исем**, икенчесе теге яки бу патриций яки плебей ыруыннан булуын күрсәтә. Өченче исем – Гракх – ~~шәхси~~ **гаилә кушаматы** булып торган. Хатын–кызлар ~~әнисенең~~ **нәсел** исемен генә йөрткәннәр. Әгәр хуҗа үз колын иреккә җибәрсә, ул аңа үз ыруы исемен биргән.

**Икенче бирем**

**Буш калган урыннарга аста күрсәтелгән сүзләрне куеп, текстны языгыз:**

Бервакыт _____ аксөякләре нәселеннән чыккан ниндидер бер бай хатын Гракхларның әниләре _______ алдында үзенең кыйммәтле _______ әйберләре белән мактана башлаган. – Ә минем бизәнү әйберләрем менә, - дип, Корнелия _______ күрсәткән. Әниләре улларына бик әйбәт тәрбия биргән.

**Сүзләр:** Корнелия, улларына, Рим, бизәнү

**Җавап:**

Бервакыт **Рим** аксөякләре нәселеннән чыккан ниндидер бер бай хатын Гракхларның әниләре **Корнелия** алдында үзенең кыйммәтле **бизәнү** әйберләре белән мактана башлаган. – Ә минем бизәнү әйберләрем менә, - дип, Корнелия **улларына** күрсәткән. Әниләре улларына бик әйбәт тәрбия биргән.

**Өченче бирем**

***Тарихи документ эзеген укып чыгыгыз, сүз кем турында барганын языгыз.***

Тыныч тормыш алып баруына карамастан, ул дәүләттә беренче кеше буларак, абыйсы өчен үч алыргамы яисә үзенең хакимиятен ныгытырга теләпме, трибун вазыйфасын башкарырга алынды.... тагында көчлерәк таләпләр, законнар кабул итте.

**Җавап: Гай Гракх турында сүз бара.**

**Дүртенче бирем:**

**Дөрес җавапны тап.**

*Китерелгән җавапларның кайсысы Тиберий Гракх кабул иткән закон?*

1)коллар ирек алганнар

2)байларның барлык җирләре дә тартып алынган

3)игенчеләр җирләргә беркетелеп куелган

4)байларның артык җирләрен тартып алып, ярлыларга бушка өләшкәннәр

**Дөрес Җавап:** 4)байларның артык җирләрен тартып алып, ярлыларга бушка өләшкәннәр

**Йомгаклау**